РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«6» июля 2019г. г. Альметьевск № 114

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлегендә халык дружинасы турында нигезләмә хакында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2014 елның 17 декабрендәге 160 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» 2014 елның 2 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлегендә халык дружинасы турында нигезләмә хакында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2014 елның 17 декабрендәге 160 номерлы карарына 1 нче кушымтага (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2018 елның 11 маендагы 118 номерлы һәм 2018 елның 15 ноябрендәге 128 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Халык дружинасы үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, әлеге Нигезләмәгә һәм башка муниципаль хокукый актларга таяна.»;

1.2. 5 нче бүлекнең 5.2 пунктындагы 4. пунктчасында «йә БМОның VII Уставы, БМО Куркынычсызлык советы яки БМО Куркынычсызлык советы тарафыннан каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында тезелгән, БМО Куркынычсызлык советы карарлары, террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән бәйле яисә

массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлеген» сүзләрен естәргә.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Шәйхетдинова Ф.А.).

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов

«АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ»